СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 8

**2019 елга сыек көнкүреш калдыкларын чыгару буенча бюджет оешмаларына һәм башка кулланучыларга күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында**

30.12.2004 елда кабул ителгән “Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларны җайга салу нигезләре турында”гы №210-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.07.2008 елда кабул ителгән “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәяләр билгеләү һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик индексларын җайга салу тәртибе турында”гы №520 карары нигезендә

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ КАРАР ЧЫГАРА:

1. НДСны исәпкә алмыйча, сыек көнкүреш калдыкларын чыгару буенча коммуналь хезмәтләргә түләү өчен тарифларны 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр календарьне бүлеп, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

2019 елның 1 гыйнварыннан 30 июня 2019 елның 30 июненә кадәр:
- бюджет оешмалары өчен - 388,73 сум - 1 м3 калдыклар өчен.
- башка кулланучылар өчен – 388,73 сум 1 м3 калдыклар өчен.

2019 елның 1июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр:
- бюджет оешмалары өчен - 400,39 сум1 м3 калдыклар өчен.
- башка кулланучылар өчен –400,39 сум 1 м3 калдыклар өчен.

2. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад, бюджет һәм эшмәкәрлек буенча комиссия рәисе Р.Ш.Газизяновка, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе К.Р.Нәҗмиевка, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше һәм инвестицияләр буенча урынбасары Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы А.Ф.Салахов

**2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр Минзәлә муниципаль районының бюджет һәм башка кулланучы оешмаларның сыек калдыкларны чыгару буенча коммуналь хезмәтләргә түләүгә тариф исәбе**

| Коммуналь хезмәтләр өчен түләү | **2018 елны календарь буенча бүлеп** | | **2019 елны календарь буенча бүлеп** | | Артуның чик индексы 1.01.2019 - 31.12.2019 елга кадәр. |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән 2019елның 31 декабренә кадәр. | |
| | НДСны исәпкә алмыйча, бюджет һәм башка оешмалар өчен | НДСны исәпкә алмыйча, бюджет һәм башка оешмалар өчен | НДСны исәпкә алмыйча, бюджет һәм башка оешмалар өчен | НДСны исәпкә алмыйча, бюджет һәм башка оешмалар өчен | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару 1 куб м чүп өчен сумнарда | 366,83 | 382,23 | 388,72 | 400,38 | 104,7 % |